ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» март 2025 ел № 137

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 декабрендәге “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 1285 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясы, 27 статьясы, 50 статьясы һәм 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 24, 26 пунктлары таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү өчен рекреацион зоналар булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләренә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 декабрендәге “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү өчен рекреацион зоналар булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 1285 номерлы карары белән расланган, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәләрнең 2 статьясындагы 2.2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.2.Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану Россия Федерациясе Су кодексының 50 статьясы нигезендә раслана торган рекреацион максатларда су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И. Ә. Галимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гатиятов